КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 13 апрель г.Казань № 280

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасында санитар-эпидемиологик хәлне һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу үзенчәлекләрен исәпкә алып Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 25 март, 218 нче, 2020 ел, 27 март, 223 нче, 2020 ел, 30 март, 234 нче, 2020 ел, 31 март, 240 нчы, 2020 ел, 03 апрель, 252 нче, 2020 ел, 06 апрель, 260 нчы, 2020 ел, 10 апрель, 272 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

10 пунктта:

«д» пунктчасының беренче абзацына «2020 елның 14 апреленә кадәр» сүзләрен өстәргә;

«е» пунктчасында «чит ил дәүләтләре» сүзләреннән соң «2020 елның 14 апреленә кадәр» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле $10^1$ пункт өстәргә:

«$10^1$. 14.04.20202020 санитар-эпидемиологик хәл яхшырганчыга кадәр, йөкләргә:

а) Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләреннән килгән (кайткан) гражданнарга:

14 календарь көн дәвамында өйдә үзизоляцияләүне тәэмин итәргә;

беренче респиратор симптомнар барлыкка килгәндә, кичекмәстән, медицина оешмаларына бармыйча, өйдә медицина ярдәме сорап мөрәҗәгать итәргә;

б) Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләреннән килгән (кайткан) гражданнар белән изоляцияне тәэмин итү чорында бергә яшәүче затларга:

14 календарь көн дәвамында өйдә үзизоляцияләүне тәэмин итәргә;

беренче респиратор симптомнар барлыкка килгәндә, медицина оешмаларына кермичә, өйдә медицина ярдәме сорап кичекмәстән мөрәҗәгать итәргә.

беренче респиратор симптомнар барлыкка килгәндә, кичекмәстән, медицина оешмаларына бармыйча, өйдә медицина ярдәме сорап мөрәҗәгать итәргә.

2020 елның 14 апреленнән Татарстан Республикасына чит ил дәүләтләре территорияләреннән килгән (кайткан) барлык затларга карата алар килгән көннән алып 14 календарь көн эчендә аларны изоляцияләү һәм обсерватор шартларында медицина күзәтүе тәэмин ителә дип билгеләргә.»;

11 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2020 елның 14 апреленнән башлап санитар-эпидемиологик хәл яхшырганга кадәр, гражданнар тарафыннан дини бүлмәләргә, биналарга һәм корылмаларга, мондый биналар һәм корылмалар урнашкан җир кишәрлекләренә бару, шулай ук әлеге объектларда һәм территорияләрдә дини йолаларда һәм тантаналарда катнашу, руханилар, шулай ук дини гамәлләр кылу һәм күрсәтелгән объектларның эшчәнлеге өчен кирәк булган затлардан тыш.».

2. Бу карар басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин